ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2020 Олы Кайбыч ав. № 283

2020 елда муниципаль ихтыяҗлар өчен төзелгән контрактларны үтәү срокларын үзгәртү мөмкинлеге турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 112 статьясындагы 65 өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020елның 11маендагы 921-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен төзелгән контрактларга (шартнамәләргә) карата яклар килешүе буенча контрактны үтәү вакытын, контрактның (яисә) бәяләрен, һәм (яисә) товар, эш, хезмәт берәмлегенең (2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 22 статьясындагы 24 өлешендә каралган очракта) бәяләрен үзгәртү дә ул 2019-nCoV тарафыннан килеп чыккан яңа коронавирус инфекциясе таралуга бәйле рәвештә башкарылганда, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән башка очракларда контрактның якларыннан бәйле булмаган, аны үтәү мөмкин булмауга китерә торган хәлләр барлыкка килгәндә рөхсәт ителә.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.
3. Әлеге карарның контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров